**ГЛАВА ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2025 елның 1 октябре — № 4

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Чертуш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 16 октябрендә Чертуш мәдәният йортында (Үзәк ур., 32 йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 13.00 сәгатькә билгеләргә.
2. 2025 елның 16 октябрендә Чертуш мәдәният йортында (Үзәк ур., 32) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 14.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Халык җыенын үткәрү өчен Чертуш авылында яшәүчеләр исемлеген аеруны сайлау тәртибен вакытлыча билгеләр буенча башкарырга кирәк.
4. Халык җыенын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Чертуш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хезмәт итүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, 85 яшьтән өлкәнрәкләр, 1 төркем инвалидларыннан тыш һәм алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү (территорияләрне чабу, чүп үләннәрне һәм үсемлекләрне юк итү өчен акча алу, эш өчен килешү буенча түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән авыл юллары чокырларын ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), кышкы чорда юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү) .

«ӘЙЕ» «ЮК».».

6. Әлеге карарны гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуцион челтәрендә бастырып чыгарырга : https://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чертуш авылындагы мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Чертуш авылы, Сөембикә урамы, 16 нчы йорты янында.

7. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы Н.М.Илалова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШАХМАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Р 05-11944/14
СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ